| МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.09.2016 г.Казань № 173/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы аппаратында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында

2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” № 273-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге “Аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында” № ПУ-701 Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъвалык итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында” № ПУ-702 Указы нигезендә,

боерык бирәм:

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы аппаратында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Кадрлар бүлеге башлыгы А.З.Кашаповка:

әлеге боерыкны Исемлеккә кертелгән вазифаларны биләүче Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре игътибарына җиткерергә;

эштән куылганда Исемлеккә кертелгән вазифаларны биләгән дәүләт гражданнарына 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясындагы чикләмәләр, бурычлар һәм җаваплылыклар турындагы нигезләмәләр хакында аңлатырга.

3. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2014 елның 23 маендагы “Аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында” № 103/2-пр боерыгын көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары М.Г. Әхмәтов

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
_____________№________
боерыгына карата кушымта

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы аппаратында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны biләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары
ИСЕМЛЕГЕ

1. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең “җитәкчеләр” категориясе вазифалары:
министрның беренче урынбасары;
министр урынбасары;
бүлек башлыгы;
бүлек башлыгы урынбасары;
сектор җитәкчесе;
Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының муниципаль районндагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы.

2. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категориясе вазифасы – министр ярдәмчесе.

3. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең “белгечләр” һәм “тәэмин итүче белгечләр” категориясе вазифалары:

3.1. Финанслау бүлегенең Татарстан Республикасы бюджетын үтәү секторындагы әйдәп баручы киңәшчесе

3.2. Финанслау бүлегенең федераль бюджетны үтәү секторындагы әйдәп баручы киңәшчесе

3.3. Финанслау бүлегенең федераль бюджетны үтәү секторындагы әйдәп баручы белгече

3.4. Финанслау бүлегенең федераль бюджетны үтәү секторындагы 1 разрядлы өлкән белгече

3.5. Финанслау бүлегенең федераль бюджетны үтәү секторындагы 1 разрядлы белгеч

3.6. Аудит һәм коррупциягә каршы эшчәнлек бүлегенең әйдәп баручы консультанты

3.7. Аудит һәм коррупциягә каршы эшчәнлек бүлегенең әйдәп баручы белгече

3.8. Инвестиция сәясәте һәм максатчан программалар бүлегенең дәүләт заказы секторындагы әйдәп баручы белгече

3.9. Аудит һәм коррупциягә каршы эшчәнлек бүлегенең 1 разрядлы өлкән

белгече

3.10. Азык-төлек базарын үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе

3.11. Игенчелек тармакларын үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе

3.12. Игенчелек тармакларын үстерү бүлегенең бөртекле һәм техник культуралар секторының әйдәп баручы киңәшчесе

3.13. Орлыкчылык һәм химияләштерү секторының әйдәп баручы киңәшчесе

3.14. Терлекчелек тармакларын үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе

3.15. Терлекчелек комплексларын үстерү секторының әйдәп баручы киңәшчесе

3.16. Ит җитештерү секторының әйдәп баручы киңәшчесе

3.17. Икътисади анализ һәм планлаштыру бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе

3.18. Хуҗалык итүнең кече рәвешләрен үстерү белегенең әйдәп баручы киңәшчесе

3.19. Хуҗалык итүнең кече рәвешләрен үстерү белегенең шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, крестьян-фермер хуҗалыкларын һәм кооперативларны үстерү буенча секторындагы әйдәп баручы белгече

3.20. Хуҗалык итүнең кече рәвешләрен үстерү белегенең шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, крестьян-фермер хуҗалыкларын һәм кооперативларны үстерү буенча секторындагы әйдәп баручы консультанты

3.21. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе

3.22. Оештыру эшчәнлеге һәм социаль үсеш бүлегенең социаль үсеш секторындагы әйдәп баручы белгече

3.23. Агросәнәгать комплексын инженерлык-техник тәэмин итү белегенең әйдәп баручы киңәшчесе

3.24. Терлекчелек һәм энергетика ресурслары объектларын механикалаштыру секторының әйдәп баручы белгече

3.25. Техник коралландыру секторының 1 разрядлы өлкән белгече.